ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 19 ноябре** **Чистай шәһәре** **№ 741**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының «Вазыйфаи затларга
административ хокук бозулар турында
беркетмәләр төзү вәкаләтләрен бирү турында»
2016 елның 22 апрелендәге 247 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Балигъ булмаганнарның аерым товарларын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына бирү турында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Вазыйфаи затларга административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләрен бирү турында» 2016 елның 22 апрелендәге 247 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексында түбәндәге статьяларда каралган административ хокук бозулар составлары исемлеген тулыландырырга:

«2.19 статья – Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итү»;

«2.20 статья – Балигъ булмаганнарга гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы булган товарларны ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны сыекландырылган углеводород газын сулау аша куллануга җәлеп итү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат сайтында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов